КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 1 декабрь г.Казань № 1545

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 – 2030 елларга Татарстан Республикасы мәдәни мирасын саклау стратегиясен раслау турында» 2017 ел, 29 декабрь, 1116 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 – 2030 елларга Татарстан Республикасы мәдәни мирасын саклау стратегиясен раслау турында» 2017 ел, 29 декабрь, 1116 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 5 ноябрь, 1011 нче; 2021 ел, 29 октябрь, 1015 нче; 2022 ел, 7 июль, 653 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2017 – 2030 елларга Татарстан Республикасы мәдәни мирасын саклау стратегиясендә:

II бүлектә:

2.12 пунктта:

беренче абзацта «матди һәм матди булмаган мираска» сүзләрен «матди мираска һәм матди булмаган этномәдәни байлыкка» сүзләренә алмаштырырга;

таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Матди мәдәни мирас | | Матди булмаган этномәдәни байлык |
|---|---|---|
| күчемсез | күчемле | |
| тарихи җирлекләр чикләрендә урнашкан күчемсез мәдәни мирас; | Россия Федерациясе Музей фонды; Россия Федерациясе Архив фонды ; | рус телендә, татар телендә, Россия Федерациясе халык-лары телләрендә һәм диа-лектларында сөйләм иҗаты, |

| | | |
|---|---|---|
| мәдәни мирас объектлары, шул исәптән истәлекле урыннар, ансамбльләр, һәйкәлләр | документларның мәҗбүри нөсхәләре фондыннан һәм китап ядкарьләре фондыннан торган милли китапханә фонды | телдән сөйләнгән традицияләр һәм аларны белдерү рәвешләре |
| | | традицион башкару сәнгате (сүз, вокаль, уен кораллары, хореография) формалары |
| | | йолаларда, бәйрәмнәрдә, гореф-гадәтләрдә, уен-көлкедә һәм халык мәдәниятенең башка формаларында чагылыш тапкан традицияләр |
| | | тарихи барлыкка килгән сюжетларда һәм образларда һәм аларны гәүдәләндерү стилистикасында, билгеле бер территориядә гамәлдә булган тормыш рәвеше һәм традицион кәсепләр белән бәйле,объектив формада, технологиядә, алар-ны күзаллау күнекмәләрендә һәм рәвешләрендә чагылыш тапкан белемнәр |
| | | матди булмаган этномәдәни байлыкның башка объект-лары»; |

2.13 пунктта:

2.13.1.1 пунктчаның өченче абзацында «Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының һәм Россия Федерациясе Региональ үсеш министрлыгының «Тарихи җирлекләр исемлеген раслау турында» 2010 елның 29 июлендәге 418/339 номерлы уртак боерыгы» сүзләрен «Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының «Россия Федерациясе тарихы һәм мәдәнияте өчен аерым әһәмияткә ия тарихи җирлекләр исемлеген раслау турында» 2023 елның 4 апрелендәге 839 номерлы боерыгы» сүзләренә алмаштырырга;

2.13.2 пунктчаның дүртенче абзацында «җиде» сүзен «алты» сүзенә алмаштырырга, «Ленино-Кокушкино» дәүләт тарихи-мәдәни музей-тыюлыгы» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.14. Матди булмаган этномәдәни байлык.

Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан региональ һәм җирле (муниципаль) әһәмияттәге матди булмаган этномәдәни байлык объектларын исәпкә алу, саклап калу, өйрәнү, актуальләштерү һәм популярлаштыру максатларында «Татарстан Республикасының Мәдәният өлкәсендә инновацияләр кертү һәм традицияләрне саклап калу буенча ресурс үзәге»

дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан Татарстан Республикасының матди булмаган этномәдәни байлык объектлары реестры алып барыла.

Татарстан Республикасының матди булмаган этномәдәни байлык объектлары реестрының бурычлары:

Татарстан Республикасы территориясендәге региональ һәм җирле (муниципаль) әһәмияттәге матди булмаган этномәдәни байлык объектлары турында мәгълүматны (материалларны) саклау һәм саклап калу өчен шартлар тудыру;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан региональ һәм җирле (муниципаль) әһәмияттәге матди булмаган этномәдәни байлык объектларын тасвирлауга (декларацияләүгә) ярдәм методик алым эшләү;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан региональ һәм җирле (муниципаль) әһәмияттәге матди булмаган этномәдәни байлык объектларын ачыклау, эзләү, сайлап алу, системалаштыру, навигацияләү мөмкинлеген оптимизацияләү;

Татарстан Республикасының матди булмаган этномәдәни байлыгы объектлары турында мәгълүматтан (материаллардан) ирекле файдалануны тәэмин итү.»;

III бүлек таблицасында:

беренче юлда:

беренче графада:

7 пунктта «республика өчен әһәмиятле яңа ике объект буенча эш башкарыла» сүзләрен «республика өчен әһәмиятле объектлар буенча эш башкарылды» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктта «зоналары проектлары расланды» сүзләрен «зоналары расланды» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктта «зоналары проектлары эшләнде» сүзләрен «зоналары расланды» сүзләренә алмаштырырга;

17 пунктта татар текстында «Традицион мәдәниятне үстерү республика үзәге тарафыннан» сүзләрен төшереп калдырырга, «мәдәни мирас» сүзләрен «этномәдәни байлык» сүзләренә алмаштырырга;

19 пунктта «мәдәни мирасны» сүзләрен «этномәдәни байлыкны» сүзләренә алмаштырырга;

21 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Татарстан Республикасының тиешле оешмалары фондларында (Татарстан Республикасы Дәүләт архивыннан башка) саклана торган китап ядкарьләре, «Милли электрон китапханә» федераль дәүләт мәгълүмат системасының бер өлеше булып торган Китап ядкарьләре реестрына кертелә.»;

икенче графада:

5 пунктта «бары» сүзен төшереп калдырырга;

10, 17, 20 – 25 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга;

14 пунктта «мәдәни мирасны» сүзләрен «этномәдәни байлыкны» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктта «мәдәни мирасны» сүзләрен «этномәдәни байлыкны» сүзләренә алмаштырырга;

18 пунктта «мәдәни мирасны» сүзләрен «этномәдәни байлыкны» сүзләренә алмаштырырга;

19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Татарстан Республикасында һәм аннан читтә матди булмаган этномәдәни байлыкны популярлаштыру буенча мәгълүмат бирү характерындагы сәясәт җитәрлек дәрәҗәдә түгел.»;

икенче юлда:

беренче графада:

12 пунктта «мәдәни мирасны» сүзләрен «этномәдәни байлыкны» сүзләренә алмаштырырга;

14 пунктта «мәдәни мирасны» сүзләрен «этномәдәни байлыкны» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктта «Татарстан Республикасы халыкларының мәдәни мирасын» сүзләрен «этномәдәни байлыкны» сүзләренә алмаштырырга;

16 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Әлеге структуралар үзара килештереп эшләсен өчен матди булмаган этномәдәни байлык объектларын саклап калу, торгызу һәм өйрәнү буенча республика башкарма хакимият органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарының, фәнни-тикшеренү оешмаларының, мәгариф оешмаларының һәм массакүләм мәгълүмат чараларының үзара хезмәттәшлеге регламентын эшләү.»;

19 пунктта «мәдәни мирас» сүзләрен «этномәдәни байлык» сүзләренә алмаштырырга;

икенче графада:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Хуҗалык һәм башка эшчәнлек башкару мәдәни мирас объектларының җимерелүенә һәм физик югалуына китерергә мөмкин.»;

3 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

10 пунктта «мәдәни мирасны» сүзләрен «этномәдәни байлыкны» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктта «мирасны» сүзен «этномәдәни байлыкны» сүзләренә алмаштырырга;

4.3 пунктның икенче абзацында «дәүләт идарәсе органнары» сүзләрен «дәүләт хакимияте органнары» сүзләренә алмаштырырга;

IV бүлектә:

4.4 пунктта:

унҗиденче абзацта «мәдәни мирасның» сүзләрен «этномәдәни байлыкның» сүзләренә алмаштырырга;

унсигезенче абзацта «мәдәни мирас» сүзләрен «этномәдәни байлык» сүзләренә алмаштырырга;

егерменче абзацта «мәдәни мирас» сүзләрен «этномәдәни байлык» сүзләренә алмаштырырга;

егерме беренче абзацта «мәдәни мирасны» сүзләрен «этномәдәни байлыкны» сүзләренә алмаштырырга;

егерме икенче абзацта «мәдәни мирасны» сүзләрен «этномәдәни байлыкны» сүзләренә алмаштырырга;

4.5 пунктта:

унберенче абзацта «мәдәни мирасның» сүзләрен «этномәдәни байлыкның» сүзләренә алмаштырырга;

ундүртенче абзацта «мәдәни мирасны» сүзләрен «этномәдәни байлыкны» сүзләренә алмаштырырга;

унҗиденче абзацта «һәм өйрәнү» сүзләрен «, өйрәнү һәм исәпкә алу» сүзләренә алмаштырырга;

V бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«V. Мәдәни мирасны саклап калуга юнәлдерелгән хокукый нормалар

Мәдәни мирасны саклап калу нигезе булып тиешле норматив хокукый база тора. Истәлекләрне саклау өлкәсендәге хокукый каркас түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

ЮНЕСКОның 1972 елның 16 ноябрендәге Бөтендөнья мәдәни һәм табигый мирасны саклау турындагы конвенциясе;

Археология мирасын саклау турында Европа конвенциясе (яңадан каралган) (Россия Федерациясендә «Археология мирасын саклау турында Европа конвенциясен ратификацияләү турында» 2011 елның 27 июнендәге 163-ФЗ номерлы Федераль закон белән ратификацияләнгән);

«Мәдәният турында Россия Федерациясе законнары нигезләре» 1992 елның 9 октябрендәге 3612-1 номерлы Россия Федерациясе Законы;

«Китапханә эше турында» 1994 елның 29 декабрендәге 78-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Россия Федерациясе Музей фонды һәм Россия Федерациясендә музейлар турында» 1996 елның 26 маендагы 54-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Халык сәнгать кәсепләре турында» 1999 елның 6 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Россия Федерациясендә архив эше турында» 2004 елның 22 октябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Россия Федерациясенең матди булмаган этномәдәни байлыгы турында» 2022 елның 20 октябрендәге 402-ФЗ номерлы Федераль закон;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тарих һәм мәдәният һәйкәлләренең, Россия Федерациясе Музей фонды предметларының, китапханә фондлары, Россия Федерациясе Архив фонды документларының, шулай ук кинофондның торышына һәм алардан файдалануга гомумроссия мониторингы турында» 2001 елның 5 июлендәге 504 номерлы карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларын канәгатьләнерлек булмаган мәдәни мирас объектларына кертү критерийларын раслау турында» 2015 елның 29 июнендәге 646 номерлы карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен) саклау зоналары турындагы нигезләмәне раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актларындагы кайбер нигезләмәләр үз көчен югалткан дип тану хакында» 2015 елның 12 сентябрендәге 972 номерлы карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен) саклап калу эшчәнлеген лицензияләү турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары үз көчен югалткан дип тану турында» 2022 елның 28 гыйнварындагы 67 номерлы карары;

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, Россия Федерациясе Җир кодексында, Россия Федерациясе Салым кодексында, «Россия Федерациясендә архитектура эшчәнлеге турында» 1995 елның 17 ноябрендәге 169-ФЗ номерлы, «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы, «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы федераль законнарда, бюджет мөнәсәбәтләрен җайга сала торган законнарда булган мәдәни мирасны саклау буенча хокук мөнәсәбәтләрен җайга салуга юнәлдерелгән кайбер нормалар;

«Мәдәният турында» 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законы;

«Халык сәнгать һөнәрләре һәм кәсепләре турында» 2005 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

«Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында» 2010 елның 14 октябрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

«Матди булмаган этномәдәни байлык өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2017 елның 26 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

«Китапханәләр һәм китапханә эше турында» 2019 елның 6 августындагы 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәдәни мирас – Зөя утрау-шәһәре һәм борынгы Болгар» комплекслы проектын раслау турында» 2010 ел, 9 декабрь, 1018 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк (республика) һәм җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына, ачыкланган мәдәни мирас объектларына, тарихый-мәдәни кыйммәткә ия булган объектларга, мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларга, хуҗалык ягыннан үзләштерелергә тиешле җир кишәрлекләренә кагылышлы тарихый-мәдәни экспертизага түләү күләмен билгеләү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 16 август, 566 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының төбәк (республика) әһәмиятендәге тарихи җирлекләре исемлеген раслау турында» 2015 ел, 26 март, 188 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектын яки җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренең) бердәм дәүләт реестрына кертү турында карар кабул итү тәртибе хакындагы нигезләмәне раслау турында» 2016 ел, 10 июнь, 393 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары торышына, эчтәлегенә, аларны саклап калуга, файдалануга, популярлаштыруга һәм дәүләт саклавына төбәк дәүләт (контроле) күзәтчелеге турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 28 сентябрь, 919 нчы карары;

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Мәдәни мирас объектлары билгеләренә ия булган объектларны ачыкланган объектлар (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) исемлегенә кертү турында» 2015 елның 16 мартындагы 264 од номерлы боерыгы;

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Мәдәни мирас объектларының торышын тикшереп тору һәм федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан ачыкланган мәдәни мирас объектларына карата системалы күзәтү чараларын үткәрүгә йөкләмә бирү тәртибен һәм аның формасын раслау турында» 2016 елның 19 июлендәге 589 од номерлы боерыгы.»;

VI бүлекнең 6.2 пунктындагы өченче абзацында «җирле үзидарә органнары» сүзләре алдына «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең» сүзләрен өстәргә;

VII бүлектә:

7.1 пунктта:

7 пунктчада «башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасының матди һәм матди булмаган мәдәни мирас объектларын» сүзләрен «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектларын һәм этномәдәни байлык объектларын» сүзләрен алмаштырырга;

13 пунктчада «матди һәм матди булмаган мәдәни мирасын» сүзләрен «матди мирасын һәм этномәдәни байлыгын» сүзләренә алмаштырырга;

17 пунктчада «матди һәм матди булмаган мәдәни мирасны» сүзләрен «матди мирасны һәм этномәдәни байлыкны» сүзләренә алмаштырырга;

7.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.2. Стратегияне гамәлгә ашыру субъектлары түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы;

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы;

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы;

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы;

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы;
Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы;
Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты;
Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты;
Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары;
«Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты» дәүләт бюджет учреждениесе;
«Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты» «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенең аерымланган структур бүлекчәсе;
«Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең А.Х.Халиков исемендәге Археология институты» «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенең аерымланган структур бүлекчәсе;
«Татарстан Республикасының Мәдәният өлкәсендә инновацияләрне кертү һәм традицияләрне саклап калу буенча ресурс үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе;
«Татарстанның Мәдәни мирас үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе;
«Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе;
«Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе;
Татарстан Республикасы дәүләт музей-тыюлыклары;
коммерциягә карамаган оешмалар;
массакүләм мәгълүмат чаралары;
башка оешмалар.»;
VIII бүлектә:
8.3 пунктта:
икенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;
дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«файдаланыла торган электрон фонд өлешен арттыру.»;
8.4 пунктта:
беренче абзацта «Татарстан Республикасының мәдәни мирасына» сүзләрен «этномәдәни байлыкка» сүзләренә алмаштырырга;
икенче абзацта «мәдәни мирасны» сүзләрен «этномәдәни байлыкны» сүзләренә алмаштырырга;
бишенче абзацта «Татарстан Республикасында Идел буе халыкларының матди булмаган мәдәни мирас объектлары бердәм электрон реестры» сүзләрен «Татарстан Республикасының матди булмаган этномәдәни байлыгы объектлары реестры» сүзләренә алмаштырырга;
алтынчы абзацта «мәдәни мирас» сүзләрен «этномәдәни байлык» сүзләренә алмаштырырга;
җиденче абзац үз көчен югалткан дип танырга;
сигезенче абзацта «мәдәни мирасның» сүзләрен «этномәдәни байлыкның» сүзләренә алмаштырырга;
8.5 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) бердәм дәүләт реестрында теркәлгән мәдәни мирас объектлары санын арттыру;»;

IX бүлектә:

9.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.6. Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) бердәм дәүләт реестрында теркәлгән мәдәни мирас объектлары санын арттыру.»;

9.12 пунктта «мәдәни мирасның» сүзләрен «этномәдәни байлыкның» сүзләренә алмаштырырга;

9.13 пунктта «мәдәни мирас» сүзләрен «этномәдәни байлык» сүзләренә алмаштырырга;

9.14 пунктта «үз этник төркеменең мәдәни мирасыннан» сүзләрен «этномәдәни байлыктан» сүзләренә алмаштырырга;

9.15 пунктта «мәдәни мирасны» сүзләрен «этномәдәни байлыкны» сүзләренә алмаштырырга;

9.16 пунктта «мәдәни мирас» сүзләрен «этномәдәни байлык» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин